| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ҖИТӘКЧЕСЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2 июль 2020 ел с.Шалты № 11

Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 ел, № 89-ФЗ, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 31.12.2017 ел, №503-ФЗ һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль законнар, «Каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданчыкларын) урнаштыру һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» 31.08.2018 ел, № 1039 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге кушымталараны расларга:

- № 1 кушымта нигезендә Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре;

- 2 нче кушымта нигезендә Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыелу урыны (мәйданчыгы) булдыруны Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты белән килештерү турында гариза формасын;

- №3 кушымта нигезендә Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыелу урыны (мәйданы) турында белешмәләр кертү өчен гариза формасы;

- 4 нче кушымта нигезендә Баулы муниципаль районы «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыелу урыннары (мәйданчыклары) реестры формасын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://www.pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында түбәндәге адрес буенча: http://www.bavly.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе — З.Х. Фаткуллин